# Татарстан Республикасы Арча районы “Түбән Аты төп гомуми белем мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорының 2019нчы елга иҗтимагый докладын

**I.Мәктәп турында информацион белешмә**

Түбән Аты төп гомуми белем мәктәбе Татарстан Республикасы Арча районы Түбән Аты авылында урнашкан. Оештырылу-хокукый формасы –муниципаль төп гомуми белем мәктәбе, оештыручысы –Татарстан Республикасының Арча районы администрациясе.
Төп мәктәпкә 2 филиал мәктәбе карый: Клачы һәм Урта Сәрдә филиал мәктәпләре.
2018-2019 нчы уку елында мәктәптә 44 (филиаллар белән) укучы белем алды:
А) башлангыч мәктәптә - 25 укучы;
Б) төп мәктәптә - 19 укучы

Классларның уртача тулылыгы:
А) башлангыч мәктәптә -уртача 4 укучы;
Б) төп мәктәптә -уртача 4 укучы;

Мәктәп буенча –уртача 9 укучы.

Мәктәптә барысы – 9класс –комплект.
А) башлангыч мәктәптә -4 (Клачы -1, Урта Сәрдә –1)
Б) төп мәктәптә -5;

.Мәктәптә барысы 15 укытучы эшли. 14-югары белемле. 1 укучы-урта профессиональ белемле. 1 педагог –югары, 11 педагог –беренче категорияле.
Укытучыларның 4есе –ир-атлар, 11 е –хатын-кызлар.Укытучыларның иң яшенә -21, иң өлкәненә 57 яшь. Уртача -43яшьтә.

Укыту-тәрбия процессын оештыру һәм алып бару өчен мәктәпнең материаль-техник базасы канәгатьләнерлек. Барлык укыту класслары кирәкле мебель, җиһаз белән тәэмин ителгән.. Укучыларга белем-тәрбия бирү процессы 1 остаханәдә, 7 кабинетта алып барыла. Мәктәптә 1 компьютер классы эшли. Мәктәпнең 0,5 га тәҗрибә мәйданчыгы, 30 урынлы ашханәсе, спортзал бар. Җиһазландырылган методик кабинет эшли. .Мәктәп тулысынча газлаштырылган, класс-кабинетларда температура режимы нормага туры килә.
Укыту-тәрбия эше бер сменада алып барыла.

**Мәктәпнең 2018-2019нчы уку елы эшчәнлеге йомгаклары.**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Түбән Аты төп гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе коллективы узган 2018-2019 нчы уку елында үзенең төп эшен 2018-2019нчы уку елына мәктәпнең методик темасы “Икенче буын ФДББСын тормышка ашыру шартларында укыту-тәрбия процессында заманча педагогик технологияләр кулланып, укучыларның сәләтләрен, укытучы потенциалын үстерү”
Мәктәп коллективының 2018-2019нчы уку елына максат һәм аны тормышка ашыру буенча бурычлар.
**Максат:** мәктәп системасы шартларында дәүләт стандартларын уңышлы үзләштерүче, сәламәт яшәү рәвеше алып баручы, сәләтле, иҗади шәхес формалаштыру.

1 . Укучыларга ныклы, сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү.
2. Укучыларның дәүләт йомгаклау имтиханнарын уңышлы тапшыруларына ирешү.
3. Икенче буын ФДББС таләпләренә туры килерлек шартлар булдыруны дәвам итү.
4. Перспективалы педагогик тәҗрибәне ачыклау һәм аны төрле дәрәҗәдәге (мәктәп, муниципаль, региональ) белем бирү берләшмәләренә тәкъдим итү.

5.Бер сыйныфта эшләүче укытучыларның һәм башлангыч, төп мәктәп укытучылары эшчәнлегендәге дәвамчанлыкны үзара яраклаштырырга.
6. Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өстендә эшләү.
7. Гаиләләр белән тыгыз элемтә урнаштырыу, тәрбия эшендә гаилә тәҗрибәсен, аларның шәхси үрнәген куллану.
8. Талантлы балаларның сәләтләрен үстерү өчен аларга һәртөрле ярдәм итү, конкурсларда, олимпиадаларда уңышлы чыгыш ясау максатыннан сәләтле укучылар белән эшчәнлекне камилләштерү.

Мәктәп коллективы шушы максатларны тормышка ашыру буенча планлы эш алып барды.

«Мәгариф турында» ТР законының балаларның белем алуга хокукын тәэмин итү турындагы статьясында күрсәтелгән бурычлар үтәлде. Ел дәвамында укуын ташлаучы, икенче елга классында кабат калучы укучылар булмады. Узган уку елын 44 укучы белән башлап, 44 укучы белән тәмамладык.

Узган уку елында 1 нче сыйныф укучылары 5 көнлек, калган барлык класслар да 6 көнлек эш режимында эшләде. Укучылар 7 уку кабинеты, 1 спорт залы, 1 китапханә бүлмәсендә шөгыльләнде. Үзебезнең җирлектә яшәгән барлык балалар да укуга тартылды һәм аларның дәрескә йөреше һәркөн системалы рәвештә контрольгә алынды, нәтиҗәләр ясалды.

Мәктәпнең укыту планы Татарстан Мәгариф һәм Фән министрлыгы раслаган региональ базис укыту планы нигезендә төзелде. Программа материалы барлык фәннәрдән дә үтелеп бетте. Укучыларга һәр фәннең үз стандартыннан чыгып белем бирелде. Өлгермәүче һәм сыйныфтан сыйныфка күчми калган укучылар булмады.

Башлангычның 4 классында 21 (филиалларда – 4), урта звеноның 5 классында 19, барлыгы 44 укучы уку елын тәмамлады.

9 классны 4 укучы уңышлы тәмамлады. Шулардан 2 се- Арча педагогик көллиятенә, 1 укучы В.Г.Тимирясов исемендәге Казан ииновацион университетның көллиятенә, Арчаның алтынчы номерлы мәктәбенә 1 укучы укырга керделәр. Чыгарылыш класс укучылары арасында бер җиргә дә укырга яки эшкә урнашмаганы юк.

## ***I. Ирешелгән уңышлар.***

### 1. __Белемлелек.__

Узган уку елында белемлелек дәрәҗәсе түбәндәгечә булды:

- Өлгереш – 100%
- Белем сыйфаты – 54%

Бу күрсәткеч алдагы уку елы белән чагыштырганда 2 %ка төште. Югары күрсәткечләр 3Б класста (өлгереш 100%, сыйфат – 100%), 3В класста (өлгереш 100%, сыйфат – 66,67%), 5А классында(өлгереш 100%, сыйфат – 100%), 6нчы класста (өлгереш 100%, сыйфат – 75%), 8 класста (өлгереш 100%, сыйфат – 66,67%). Иң түбән күрсәткеч 3А классында(өлгереш 100%, сыйфат – 0%), 8А классында (өлгереш 100%, сыйфат – 0%), 2 нче класста (өлгереш 100%, сыйфат – 37,5%).

Менә соңгы 5 елга күрсәткечләр түбәндәгечә:

| Уку елы | Отличниклар | Алдынгылар | Белем сыйфаты |
|---|---|---|---|
| 2013-2014 | 3 | 26 | 62% |
| 2014-2015 | 8 | 22 | 58% |
| 2015-2016 | 8 | 26 | 70% |
| 2016-2017 | 7 | 20 | 60% |
| 2017-2018 | 5 | 18 | 56% |
| 2018-2019 | 4 | 16 | 54% |

**Арадаш аттестация эш нәтиҗәләре буенча түбәндәгечә булды.**

РФ дә Мәгариф турында” законның 58 нче статьясы нигезендә 2-9 сыйныфларда арадаш аттестация махсус расписание буенча узды. Барлык бала да уңышлы тапшырып сыйныфтан –сыйныфка күчерелде.

**2018 – 2019 нче уку елында йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре**
**ДЙА шартларында педагогик коллективның эшчәнлеге**

**IX класс:**

2018-2019нчы уку елында 4 укучы математика, рус теле, химия, география, информатика, тарих һәм җәмгыять белеменнән имтихан тапшырдылар.

Нәтиҗәләре начар булмады.

Математикадан ”5”гә 1 укучы, 3 укучы “4”гә эшләде. Өлгереш 100%, сыйфат 100% тәшкил итә.

Рус теленнән 2 укучы “5”гә, 1 укучы – “4”гә, 1 укучы – “3”гә эшләде. Өлгереш 100%, сыйфат 75% тәшкил итә.

Җәмгыять белеменнән имтиханны бер укучы бирде. Ул аны “4”гә тапшырды. Өлгереш 100%, сыйфат 100% тәшкил итә.

Географиядән имтиханны ике укучы бирде. ”5”гә 1 укучы, 1 укучы “4”гә эшләде Өлгереш 100%, сыйфат 100% тәшкил итә.

Информатикадан өч укучы тапшырды.2 укучы “5” гә, 1 укучы “4”гә язды.. Өлгереш 100%, сыйфат 100% тәшкил итә.

Химиядән 1 укучы имтиханны “5”гә тапшырды. Өлгереш 100%, сыйфат 100% тәшкил итә.

Тарихтан бер укучы бирде. Ул аны “4”гә тапшырды. Өлгереш 100%, сыйфат 100% тәшкил итә.

| Предмет | Доля выпускников, сдавших ГИА на “2” | | Доля выпускников, сдавших ГИА на “3” | | Доля выпускников, сдавших ГИА на “4” | | Доля выпускников, сдавших ГИА на “5” | | Средний балл | | Средняя оценка | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2018 | 2019 | 2018 | 2019 | 2018 | 2019 | 2018 | 2019 | 2018 | 2019 | 2018 | 2019 |
| Математика | - | - | 16,67 | 0 | 66,67 | 75 | 16,67 | 25 | 16,41 | 19,25 | 3,91 | 4,5 |
| Русский язык | - | - | 33 | 25 | 25 | 25 | 42 | 75 | 31,41 | 35 | 4,08 | 4,25 |
| Биология | - | - | 0 | | 50 | | 50 | | 34,5 | - | 4,5 | - |
| Информатика | - | - | 40 | 0 | 60 | 50 | 0 | 50 | 12,4 | 18 | 3,6 | 4,5 |
| Химия | - | - | 0 | 0 | 57,14 | 0 | 42,85 | 100 | 25,57 | 31 | 4,42 | 5 |
| География | - | - | 20 | 0 | 60 | 0 | 20 | 100 | 24,2 | 29,5 | 4 | 5 |
| Обществознание | - | - | - | 0 | - | 100 | - | 0 | - | 29 | - | 4 |
| История | - | - | - | 0 | - | 100 | - | 0 | - | | - | |

Гомуми алганда балаларның төп фәннәрдән белем дәрәҗәләре югары. Димәк, һәр предмет укытучысы узган елгы имтихан нәтиҗәләрен анализлап укучыларга ныклы белем бирү юлларын ачыклау өстендә системалы эш алып барырга тиеш. Укучылар белән индивидуаль эш мәсьәләсе дә иң төп бурычларның берсе булырга тиеш. Көчле, сәләтле

укучылар белән эшне яхшыртасы бар. Укучыларны да, әти-әниләрне дә ТДИга уку елы башыннан ук хәзерләү бурычы куела.

Фән нигезләрен авырдан үзләштерүче укучылар белән түбән класслардан ук планлы эш алып барырга.

Имтиханнарга әзерлек план нигезендә алып барылды. Администрация тарафыннан укучылар Һәм әти-әниләр белән даими рәвештә җыелышлар үткәрелде, аңлату эшләре алып барылды, имтихан тестлары буенча административ контроль эшләр үткәрелде. Укучылар интернет челтәрендәге һәр яңалыкны консультацияләр вакытында кулландылар. СТАТГРАД, Решу ОГЭ һәм башка сайтлар үткәргән диагностик тестларда катнашып, имтиханнарга әзерлек дәрәҗәсен билгеләп, хаталар өстендә эшләделәр. Кышкы каникулда математика һәм рус теленнән, язгы каникулда барлык фәннәрдән сынау имтиханнары үткәрелеп, анализ ясалды. Фән укытучылары да, укучылар да, әти-әниләр дә имтиханнарга җаваплы карадылар. ТДИны укучының уңышлы тапшыруына ирешү өчен, фән укытучысы, класс җитәкчесе, әти-әниләрнең бердәм эшчәнлеге кирәк. Барыбыз да бердәм эшләгәч, нәтиҗәләр дә куанычлы булды. Бер фәннән дә минималь балл җыя алмаган, аттестат тапшырылмаган укучы булмады

***Башлангыч һәм төп белем бирү эшендә дәвамчылык.***

2018 – 2019нчы уку елында башлангыч һәм урта мәктәп эшендә өзеклек булдырмыйча дәвамчылыкны булдырып эшләргә аеруча әһәмият бирелде. Чөнки бер укытучыга гына ияләшкән укучылар өлкән классларга киткәч югалып калалар, алай гына да түгел үзләштерү дәрәҗәсе ягыннан үсеш булмый. Шунлыктан мәктәп дирекциясе һәм мәктәпнең методик советы башлангыч класс һәм фән укытучылары белән даими рәвештә семинарлар үткәрә. Педсовет утырышларында докладлар тыңланды. 2018 – 2019 уку елы дәвамында үткәрелгән атналыклар, ачык дәрес һәм дәрестән тыш чаралар дәвамчанлыклы үстерүгә юнәлтеп үткәрелде. Нәтиҗәдә фән укытучылары башлангычтан килгән укучыларның индивидуаль сәләтләрен, психологик үзенчәлекләрен яхшы беләләр. Башлангыч класс укытучылары фәннәрне югары классларда укытуга булган таләпләрне аңлап балаларны яшьтән югары классларда белем алуга әзерлиләр. Бу үзара тәҗрибә алышу гына түгел, һәр укытучыны иҗади эшләргә этәрүче стимул ролен дә үти, үзара ярышка һәм иң мөһиме үз белемеңне даими күтәрүгә этәрә.

**Мәктәп һәм балалар бакчасы арасында хезмәттәшлек**

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны мәктәпкә әзерләү максатында, балалар бакчасы белән системалы эш алып барыла. Башлангыч сыйныф укытучылары һәм бакча тәрбиячеләре бер-берсенең дәресләрендә булалар. Яңа уку елында беренче сыйныфны кабул итәчәк Дәүлиева Алсу Рәсим кызы занятиеләрдә, бәйрәмнәр, балалар иртәләрендә булып укучыларны өйрәнде. Шулай ук әлеге балаларны берничә тапкыр мәктәпкә чакырып таныштыру, кызыксындыру, өйрәнү тибындагы дәресләр үткәрелде.

**Методик эшчәнлеккә анализ**

Укытучыларның педагогик осталыкларын күтәрүнең мөһим чарасы, мәктәп эшен системага салучы булып, методик эш тора. Хәзерге заман шартларында тәрбия алымнарын, яңа методикаларны рациональ һәм оператив куллануда мәктәптә методик эшнең роле тагын да арта.

Уку елы дәвамында мәктәптә методик эшчәнлек "Икенче буын ФДББСын тормышка ашыру шартларында укыту-тәрбия процессында заманча педагогик технологияләр кулланып, укучыларның сәләтләрен, укытучы потенциалын үстер" темасы өстендә дәвам итте һәм түбәндәге бурычларны күзаллады:

- Заманча технологияләр кулланып, белемнең сыйфатын күтәрү өстендә эшне дәвам итәргә.
- Укытучыларның педагогик осталыкларын күтәрү эшен көчәйтергә, педколлектив әгъзаларының ФГОС ны өйрәнүен, курсларда булуын тәэмин итәргә.
- Укучыларны фәнни-тикшеренү, проект эшчәнлегенә тартырга һәм фәнни-практик конференцияләрдә, конкурсларда актив катнашырга.
- Белем алырга сәләтле укучылар белән эшчәнлекне арттырырга, аларның фән олимпиадаларында, интеллектуаль марафоннарда катнашуын тәэмин итәргә.
- Педагогик совет эшчәнлегенең яңа форма һәм методларын эзләргә.
- Мәктәпнең материаль-техник базасын ныгыту буенча эшне дәвам итәргә.

2018-2019 нче уку елында түбәндәгеләргә игътибар арттырылды.
1.Белем бирүнен сыйфатын яхшырту. Отличниклар һәм ударниклар санын арттыру.
2. 1 ай дәвамында 1, 5 класс укучыларынын адаптация чорын өйрәнү.
3. Сәләтле укучылар белән индивидуаль эш оештыру.
4. Фәннәрне авырдан үзләштерүче укучылар белән планлы рәвештә эш оештыру.
5. Мәктәп һәм район олимпиадаларында зур әзерлек белән катнашу, район олимпиадаларында призлы урыннар алу өчен көрәшү.

Мәктәп коллективы алдына куйган бурычлар дәрес методикасын камилләштерү, сәләтле һәм фәннәрне авырдан үзләштерүче укучылар белән төрле эш формалары оештыру, укучыларда укуга омтылыш тәрбияләү, укытучыларны яңа методик һәм педагогик әдәбият белән таныштыру аша үтәлде. Методик эшне оештырганда, төрле формалар кулланылды.

- ✓ Методсовет
- ✓ Методик берләшмәләр
- ✓ Үзбелемеңне күтәрү өстендә эш
- ✓ Ачык дәресләрне анализлау
- ✓ Фән атналыклары
- ✓ Педагогик мониторинг
- ✓ Укытучыларга ярдәмгә методик рекомендацияләр – стендлар эшләү
- ✓ Дәрес оештыру һәм үткәрү буенча индивидуаль әңгәмәләр
- ✓ Курсларда булуны оештыру
- ✓ Аттестация

2018-2019 нче уку елында методик совет каршында 4 методик берләшмә үз юнәлешләре буенча эшчәнлек оештырды. Һәр берләшмә үз алдына укытучыларның һөнәри осталыгын үстерү; укучыларның кызыксынулары, сәләтләре һәм мөмкинлекләрен ачыклап, төрле интеллектуаль конкурсларда катнаштыру; укытучыларны һәм укучыларны проект һәм тикшерү эшчәнлегенә киңрәк тартуны төп бурыч итеп куйды.

Һәр методик берләшмә үз эшен план нигезендә алып барды. Берләшмә утырышларында түбәндәге мәсьәләләр каралды:
1.Узган уку елына анализ, яңа уку елына эш планын, укытучыларның календар-тематик планнарын раслау.

2. Фән атналыкларын планлаштыру.
3. Сәләтле укучылар белән эш оештыру. Олимпиадаларның мәктәп турларын әзерләү һәм үткәрү, район, республика турларында катнашу.
4. Фәнни-тикшеренү, проект эшләре белән төрле конкурсларда катнашу.
5. Укучыларның фәнни-гамәли конференциясен үткәрү.
6. ГИА га әзерлек.

Методик темалар буенча ачык дәресләр һәм класстан тыш ачык чаралар күрсәтелде, укытучылар бу эштә актив катнашты.

Мәктәп администрациясе һәм методик берләшмәләрнең мөһим бурычы – укытучыларга өзлексез белем биреп (курслар), аларның педагогик осталыкларын күтәрү һәм аттестация аша квалификацияләрен күтәрүне стимуллаштыру.

Мәктәптәге методик берләшмәләргә 100 % укытучы кергән. Педсоветлар һәм методик совет утырышлары тематикасы мәктәп проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән.

7 кешелек составтан торган методик совет белән укыту эшләре буенча директор урынбасары җитәкчелек итте. Методик совет утырышларында түбәндәге мәсьәләләр каралды:

- Яңа уку елында методик эшчәнлеккә анализ, яңа уку елына эш планлаштыру;
- тематик педсоветларга әзерлек;
- 1, 5  класс укучыларының адаптация чорын өйрәнү;
- олимпиадаларның мәктәп турларын әзерләү һәм үткәрү;
- олимпиадаларның район турлары нәтиҗәләре;
- эчке контроль планы буенча контроль эшләр үткәрү, аларны анализлау;
- фән атналыкларына әзерлек;
- укучыларны фәнни-тикшеренү эшенә тарту буенча эшчәнлек;
- укытучыларны аттестациягә әзерләү;
- имтиханнарга әзерлек;
- 2018-2019 нчы уку елы йомгаклары, яңа уку елына әзерлек;
- 2019-2020 нче уку елына план төзү.

Укытучылар тарафыннан, тәҗрибә уртаклашу максатында, мәктәп күләмендә һәм район семинарларында ачык дәресләр, дәрестән тыш чаралар күрсәтелде. Ләкин ачык дәрес һәм чаралар күрсәтү, үзара дәресләргә керү җитәрлек дәрәҗәдә булмады. Укытучылар төрле конкурсларда актив катнаштылар һәм матур нәтиҗәләргә ирештеләр.Математика укытучысы Шәмсетдинова Ф.Ф. “Ел сыйныф җитәкчесе” конкурсының зона этабында катнашты. Ингиз теле укытучысы Әхтәмова А.С. “Ел укытучысы-2019” конкурсының зона этабында катнашты.

**Нәтиҗә :** профессиональ конкурсларда, проектларда катнашу, сәләтле укучылар белән эшләү өчен коллективның бөтен мөмкинлекләре дә бар, администрация тарафыннан һәр башлангыч эш хуплана гына. Әлеге өлкәдә эшлисе дә эшлисе. Бу һәрберебезнең төп бурычы булырга тиеш.

Методик берләшмә утырышларында һәр фән укытучысының эш программалары карап расланды. Мәктәпнең методик берләшмәләре укучыларны йомгаклау аттестациясенә әзерләү буенча актив эш алып бардылар.

Коллективның һәр педагогы үз белемен күтәрү, елдан-ел камилләштерү өстендә системалы эш алып барырга тиеш. Бу юнәлештә дә укытучыларның эшчәнлеге планлы рәвештә алып барыла. Һәр укытучы үз белемен күтәрү планы буенча максатчан эшли, белем күтәрү курсларында була. Узган уку елы дәвамында 5 укытучы белем күтәрү курсларында булды.

**Нәтиҗәләр:**

1. МБ утырышларының тематикасы МБ алдында торучы төп проблемалы сорауларны чагылдыра.
2. Контрольнең төп юнәлешләре һәм дәресләргә йөрү тематикасы дөрес сайланган. Бу укыту сыйфатын, дәрес структурасын, дәрестә кулланыла торган метод һәм формаларны сайлап алуны яхшыртуга ярдәм итә.
3. Хаталарны төзәтү һәм коррекцияләү буенча тәкъдимнәр оператив киңәшмәләрдә, методик совет, методик берләшмәләр утырышларында, директор алды киңәшмәләрендә бирелә.

**Тәкъдимнәр:**

1. МБ эшчәнлегенең нигезе итеп, уку материалының төп темалары буенча предметара бәйләнешне алырга.
2. Төп игътибарны дәрес оештыруның формаларын һәм методларын камилләштерүгә юнәлтергә.
3. Алдынгы тәҗрибәне үзләштерү, гомумиләштерү һәм үз эшчәнлегенә кертү өстендә эш алып барырга.
4. МБ рамкаларында семинар – практикумнар ешрак үткәрергә.
5. Дәрескә әзерләнү һәм дәресне үткәрү барышында планлаштыруга һәм реализацияләүгә аерым игътибар бирергә.
6. Үзара дәресләргә йөрешне укытучыларның индивидуаль ихтыяҗларыннан чыгып планлаштырырга.

## Педагогик аттестация торышына анализ

2018 - 2019 нчы уку елында Түбән Аты төп гомуми белем бирү мәктәбендә барлыгы 15 педагог эшләде. Коллективның һәр педагогы үз белемен күтәрү, елдан-ел камилләштерү өстендә системалы эш алып барырга тиеш. Бу юнәлештә дә укытучыларның эшчәнлеге планлы рәвештә алып барыла. Һәр укытучы үз белемен күтәрү планы буенча максатчан эшли, белем күтәрү курсларында була. Узган уку елы дәвамында 5 укытучы белем күтәрү курсларында булды.

Бу уку елында Хәмидуллина З.Я. һәм Закирова А.Р. аттестация үттләре. Хәмидуллина З.Я. беренче категорияне раслатты. Закирова А.Р. беренче категриягә ия булды. Уку елы дәвамында аттестациягә керүче укытучылар белән эш оештырылды, эксперт комиссияләргә ачык дәресләр, чаралар күрсәтелде, аларның эшчәнлеге тикшерелде һәм анализланды. Укытучылар аттестацион курсларда тиешле вакытларында белем алдылар.

Уку елына куелган укытучыларның категорияләрен күтәрү бурычын соңгы елларда үтибез. 2014-2015 нче уку елында – 1 укытучы, 2015-2016 нчы уку елында 1 укытучы, 2018-2019 нчы уку елында 1 укытучы квалификацион категориясен күтәрде. Беренче категориясе булмаган ике укытучы калды, икесе дә 2020-2021 нче уку елында категория алу өчен гариза язачаклар. Борчыган мәсьәлә булып, укытучыларның югары квал. категория алырга теләмәүләре тора. Югыйсә хезмәтләре һәм тәҗрибәләре белән моңа лаек укытучыларыбыз юк түгел. әлбәттә, укытучының төп максаты категория алу түгел, ә ныклы белем бирү. Бу максатны барлык укытучылар да тормышка ашырырга тырыша.

**Нәтиҗә:** педагогик коллективның квалификацион категорияләрен күтәрү өстендә эшне системалы дәвам итәргә.

***Китапханә эшчәнлеге.***

**I.** 2018-2019 уку елында китап фонды 5503 данә тәшкил итте. Шуларның 1355 е дәреслек, 1548 сы дидактик материал, 2600 матур әдәбият. 2018-2019 уку елы дәвамында 22 китап алып кайтылды (22 дәреслек). Яңа уку елында 1-9 класс укучыларының дәреслек белән тәэмин ителеше 100 % булды.

Китап белән тәэмин ителеш бер балага 20 китап;

Йөреш: башлангыч класс укучылары – 5;

5-9 класс укучылары – 4.

Укылыш: 10 китап.

**II.** Китапханә даими эшли.

Китапханәнең уку залы юк, укучы китапларны үзе сайлап ала.

Укучыларга информационно – библиографический хезмәт күрсәтелә, алфабитлы каталог төзелгән, аның белән ничек эшләргә укучыларга даими рәвештә китапханә дәресләрендә өйрәтелеп барыла.

Китапханә советы яңартылды ( һәр класстан бер укучы ). Бу “Яшь китапханәче” әгъзалары аена бер тапкыр китап тотылышын тикшерү буенча рейдлар үткәрделәр. Иске китапларны ремонтлау буенча даими эш алып барылды. Мәсәлән, 5 нче һәм 6 нчы класс укучылары бу эштә бик теләп катнаштылар.

Ел давамында үткәрелгән китап күргәзмәләре укучыларда зур кызыксыну уятты. Мәсәлән, Г.Тукай, М. Җәлил, Бөек Җинүнең 74 еллыгына, Арча районыннан чыккан шәхесләргә багышлап, төзелгән китап күргәзмәсе укучыларга бик охшады. 12 нче апрельдә Космонавтика көне уңаеннан чаралар үткәрелде. Белем бәйрәмен, укытучылар көнен, көзге балл, яңа ел, 8 Март, соңгы звонок бәйрәмен әзерләшү, үткәрешүдә актив катнашылды. Программа нигезендә китапханә дәресләре үткәрелеп барылды. Дәреслекләр дәреслекләрнең электрон фондына (ЭФУЛ) тутырылды.

Газета-журналларга язылу да әйбәт кенә үтте. Укучылар “Сабантуй”, “Тылсымлы куллар” ,”Салават күпере” журналларына язылдылар. Һәр укытучы “Арча хәбәрләре” газетасына “Мәгариф” һәм “Гаилә һәм мәктәп” журналларына, укытучылар коллективы мәктәп өчен “Казан утлары” һәм “Сөембикә” журналларына язылдылар.

**III.** Бурычлар:

1. Дәреслекләр белән тәэмин итү буенча оператив эш алып бару.
2. Китапларны ремонтлауга тарту.
3. Дәреслекләрнең электрон фондын (ЭФУЛ) даими яңа кайткан китаплар белән тулыландыру .

***Кайнар аш белән тәэмин ителеш.***

Мәктәптә барлык укучылар да түләүсез кайнар аш белән тәэмин ителде. Укучыларны ашату тиешенчә җиһазландырылган ашханәдә оештырыла. Ашату 3 сменага бүлеп оештырыла. Ашханә санитария-гигиена таләпләренә туры килә.

Мәктәп администрациясе укучыларны дөрес һәм яхшы сыйфатлы, рациональ ашату мәсьәләсенә зур игътибар бирә. Ашханәдә санитар-гигиеник таләпләр үтәлә, чисталык, җылылык канәгатьләнерлек. Пешерелгән ризыклар яхшы сыйфатлы. Рацион төрлеләндереп торыла. Менюга даими рәвештә яшелчә ризыклары кертелә.Бюджеттан 5 сум 70 тиен акча бирелә. Мәктәп яны тәҗрибә участогында укучыларны ел буена тәэмин итәрлек яшелчә (кишер, чөгендер, суган, кыяр, помидор) үстерелә.

Учет эше тиешле югарылыкта алып барылды, ашханәдә көн саен укучылар дежур тордылар.

Әти-әниләр балаларны мәктәп ашханәсендә ашатудан канәгать .
Мәктәп яны тәҗрибә мәйданчыгы һәм андагы хезмәт белән Закирова А.Р. җитәкчелек итте. Эш яхшы оештырылды, күп кенә тәҗрибәләр куелды. Җәй коры килүгә карамастан, укытучы һәм укучыларның намуслы хезмәте нәтиҗәсендә, быел да чагыштырмача мул уңыш үстерелде. Үсеп килүче организмның туклануын дөрес оештыруның мөһимлеген һәрберебез аңлый. Укучыларны, әти-әниләрне дөрес туклану кагыйдәләренә өйрәтүгә басым ясыйбыз. Бу максаттан әти-әниләргә гаиләдә төрле яшьтәге балаларның дөрес туклануын дөре оештыру кирәклеген аңлата торган чыгышлар, әңгәмәләр тәкъдим итәбез.

***Тәҗрибә участогы эшчәнлеге.***

Түбән Аты төп гомуми белем мәктәбе тәҗрибә участогы 0,17 га мәйдан били. Әлеге мәйданда яшелчә культуралары, чәчәклек, орлыкчылык, тәҗрибәчелек , дару үләннәре һәм башлангыч класслар бүлекләре бар

Һәр елны август аенда мәктәбебез район күләмендә оештырылган ярминкәләрдә катнашып килә. Тәҗрибә участогында үстерелгән җиләк – җимеш, яшелчә, чәчәкләр районыбыз халкына тәкъдим ителә.

Җәйге каникул чорында укучылар дежур укытучы җитәкчелегендә мәктәп яны тәҗрибә участогында шактый гына эшләр башкардылар, чүп утадылар, су сиптеләр.

***Хезмәтне саклау, пожар куркынычсызлыгы һәм гражданар оборонасы***

Узган уку елында хезмәтне саклау, техника куркынычсызлыгы, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү буенча шактый чаралар күрелде. Мәктәпнең эш планының эчке контроль өлешендә хезмәтне саклау буенча махсус бүлек булдырылды, конкрет контроль юнәлешләре билгеләнде.

Педколлектив һәм ярдәмче персонал уку елы башында хезмәтне саклау, техника куркынычсызлыгы, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү буенча мәктәп директорының приказы белән таныштырылды.

1сентябрь көнне һәр класста укучыларга кереш инструктаж, ә ОБЖ, физкультура, информатика, физика, химия, технология, биология укытучылары беренче дәрестә, алга таба эшчәнлек төре үзгәргәндә укучыларга эш урынында беренчел инструктаж үткәрделәр, яңа килгән педагог һәм техник хезмәткәрләргә эш башлауның беренче көнендә кереш һәм эш урынында беренчел инструктаж үткәрелде.

Барлык үткәрелгән инструктажларны теркәп бару өчен махсус инструктаж журналлары булдырылды.

Барлык укыту кабинетларында, ярдәмче биналарда, мастерскойда, гаражда, ашханәдә хезмәтне саклау буенча конкрет инструкцияләр эшкәртеп эленде, экстремаль шартларда яки янгын куркынычы булганда махсус эвакуация планы булдырылды.

Үткәрелгән инструктажлар класс журналларында билгеләнде.

Хезмәтне саклау буенча күп баскычлы регистрация журналы алып барылды.

Һәр педагогка һәм техник хезмәткәргә вазифа инструкцияләре эшләнде, бер данәсе хезмәткәргә бирелде, бер данәсе локаль актлар журналына беркетелде.

Укучылар һәм хезмәткәрләр өчен кереш һәм эш урынында беренчел инструктаж үткәрү программасы эшләнде, класс җитәкчеләренә, укытучыларга таратылды.

Янгын куркынычы булган очракта оешкан эвакуация үткәрү буенча чирек саен практик репетиция үткәрелде.

Узган уку елында хезмәткәрләр белән эш вакытында, укучылар белән укыту -тәрбия процессында, мәктәптән тыш чараларда бәхетсезлек очраклары булмады.

Укучылар көзге, кышкы, язгы һәм җәйге каникулга таралыр алдыннан, аларга махсус инструктаж үткәрелә, аерым бланкка теркәлеп, мәктәптә ел буе саклана.

Укыту кабинетларына уку елы башланыр алдыннан, санитар-гигиеник торышын һәм хезмәтне саклау нормаларының булуын исәпкә алып, акт-рөхсәт бирелде.

## 2. <u>**Тәрбиялелек һәм сәламәтлек.**</u>

Укучыларның тәрбиялелек дәрәҗәсен үстерү аларның белемлелек дәрәҗәсен күтәрү кебек үк әһәмияткә ия. Укытучылар коллективы укучыларның тәрбиялелек дәрәҗәсен үстерүгә зур игътибар бирә. Барлык класс сәгатьләре, һәр дәрес укучыларда милли аң тәрбияләү, милли – төбәк компонетларына, халык педагогикасы традицияләренә таянып алып барыла.

Укучыларның сәламәтлеген саклау- мәктәп коллективы өчен иң зарури бурычларның берсе.

Спорт – сәламәтләндерү сәгатьләре, дөрес итеп тукландыру, расписаниегә дәресләрне СанПиН таләпләренә туры китереп урнаштыру, акыл эшчәнлеген физик күнегүләр белән чиратлаштырып алып бару, иртәнге гимнастика, дәресләрдә физкультминутларын даими уздыру һ.б. – барысы да сәламәтлек программасын тормышка ашыруга юнәлдерелгән. Менә берничә ел рәттән инде мәктәптә  башлангыч класслар өчен ял лагеры,өлкән сыйныф укучылары өчен хезмәт лагеры уңышлы гына эшләп килә.

Шәхесне мөстәкыйль тормышка әзерләү (социализация) - иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. Мәктәп үзенең эшчәнлеген хезмәт тәрбиясе бирү белән бергә үреп алып бара. Авыл баласы ел дәвамында теге я бу эшкә тартыла.

Җәй көне укучыларның бер өлеше күмәк хуҗалыкта, мәктәп яны тәҗрибә участогында эшли. Алар бу эшләр вакытында байтак кына күнекмәләр дә алдылар, мондый эшләр укучыларга профориентацион тәрбия бирүдә дә әһәмияткә ия.

V – XI класс укучылары ел буе өлкәнннәргә булыштылар: даими рәвештә шәфкатьлелек рейдлары уздырдылар.

Класстан тыш тәрбия чараларында укучыларыбыз бик теләп катнашалар, призлы урыннар яулыйлар.

### *3.Укыту тәрбия процессын оештырудагы уңышлар.*

Коллектив “Икенче буын ФББBСын тормышка ашыру шартларында тәрбия бирүдә һәм белем бирүдә яңа технологияләр, формалар, метод һәм алымнарны үзләштерү аша укучыларның белем сыйфатын камилләштерү” дигән тема астында эшләде. Мәктәптә

үстерешле укытуга зур игътибар бирелә. Россия, Татарстан, район, мәктәпнең алдынгы укытучылары тәрбиясе өйрәнелә һәм практикада кулланыла. Һәр укытучы үз эшенә якын килеп эшләргә омтылды. Дәүлиева А.Р., Даутова Р.Г., Хамидуллин Д.М ., Хамидуллина З. Я. әнә шундый укытучылардан. Укучылар район олимпиадаларында татар теле ,җәмгыять белеме фәннәре буенча призлы урын яуладылар. Укучыларның уңышларында аларны әзерләгән Хамидуллина З. Я., Кашшапов Ф.Х..ларның өлеше зур.

Укучыларны ДЙАга әзерләгәндә укытучының роле гаять дәрәҗәдә зур. Бу юнәлештә өлкән классларда белем бирүче укытучылар мәсьәләне дөрес аңлап, әти-әниләр белән даими эш алып барган, өстәмә шөгыльләнеп укучыларны ДЙАга әзерләделәр. Нәтиҗәләр әйбәт. Күрсәткечләр республиканыкыннан югары. Укучыларны ДЙАга әзерләүдә математика рус теле укытучысы Хасанова Э.И.,математика, информатика укытучысы Шамсетдинова Ф.Ф.ларның роле көчләрен кызганмый эшләүләре мактауга лаек.

4 чыгарылыш укучыга төп гомуми белем турында аттестат тапшырылды.

***4.Тәрбия эшенең нәтиҗәлелеге.***

2018-2019 нчы уку елында мәктәптә укыту процессы белән берррәттән , дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда әхлак, экологик рухи һәм физик тәрбияне үстерү, сәләтле балалар белән эш алымнарын камилләштерү проблемасын тормышка ашыруга юнәлдерелгән күпкырлы тәрбияви эшчәнлек алып барылды.

Бу уку елында педагогик коллектив алдына түбәндәге бурычлар куелган иде:

1. Педагогик технологияләрне тәрбия процессына кертү ярдәмендә укучыларның танып белү активлыгын үстерергә һәм интеллектуаль үсешенә ирешергә.
2. Укучылар үзидарәсен үстерү ярдәмендә укучыларның мөстәкыйльлеген, җаваплылыгын арттыруга ирешергә.
3. Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү, үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудырырга.
4. Әти-әниләр белән тыгыз элемтә булдырырга, педагогиканың мөһим проблемалары буенча укулар оештырырга

Алга куелган бурыч – максатларны тормышка ашыру өчен мәктәп коллективы системалы эш алып барды. Тәрбия эшчәнлеген оештыруда укытучылар, класс җитәкчеләре катнашты. Алар укыту процессын сыйныфтан һәм мәктәптән тыш чаралар белән бәйләп алып бару өчен, һәр баланың яшь үзенчәлекләрен, мөмкинлекләрен, сәләтләрен исәпкә алып, аларда укуга булган карашларын уңай якка үзгәртергә тырышып, кызыксындыру тудырып, халкына карата лаеклы варис булу, эшлекле, сәламәт, белемле шәхес тәрбияләү өчен план нигезендә эшләде.

Тәрбия эше түбәндәге юнәлешләргә таянып алып барылды: Танып белү; Патриотик һәм гражданлылык; Хокукый; Спорт-сәламәтләндерү; Хезмәт; Әхлак; Эстетик; Экологик юнәлеш.

Танып белү юнәлешендәге тәрбия эшен тормышка ашыру максатыннан мәктәптә фән атналыклары, компьютер, интерактив librarya такталар ярдәмендә тәрбияви дәресләр үткәрелде. 2 нче сентябрь көнне һәр сыйныф җитәкчесе ныклы әзерлек белән “Тынычлык һәм шәфкатьлелек” дәресе үткәрде. Укучылар ел саен Бөтенроссия күләмендә үткәрелә торган “Русский медвежонок”, “Зирәк тиен”, “Көнгерә”, “КИТ”, “С чистого листа”, уен-конкурсларында, республика һәм район күләмендә үткәрелә торган ярышларда, фәнни-конференцияләрдә актив катнаштылар һәм матур күрсәткечләргә ирештеләр.

Апрель аенда мәктәптә Балалар китабы атналыгы үтте. Атналык кысаларында “Минем яраткан китабым” тематик күргәзмәсе. “Яраткан әкиятләребез” темасына рәсемнәр конкурсы, авыл китапханәсенә экскурсия, викторина-конкурслар оештырылды. “Спортивный Татарстан» исеме астында шәфкатьлелек атнасы оешкан төстә үтте. “Юнармия” отряды эшчәнлеген активлаштырасы бар.

Укучыларга патриотик һәм гражданлык юнәлешендә тәрбия бирү максатыннан системалы рәвештә эш алып барылды. Балалар иминлеге айлыгы кысаларында “Саклан!Башкаларны да сакла!” дип исемләнгән мәктәпкүләм чара оештырылды. Мәктәбебездә хәтер көнен билгеләп үтү, үз халкыбызның күренекле уллары һәм кызлары булган шәхесләрне искә төшерү, аларга багышлап тәрбия сәгатьләре үткәрү, Россия һәм Татарстан Конституциясе кабул итү көннәрен, Яшь антифашистлар көненә багышланган класс сәгате, Наласа урта мәктәбендә үткән “Форпост “ отрядлары арасында үткәрелгән ярышта актив катнаштылар, интернационалист- сугышчыларның каберләрен чистартып тору,Халыклар бердәмлеге көнен билгеләп үтү матур традициягә әйләнеп бара. «Татарстан-2030: республикам киләчәгемә керткән өлешем” темасына парламент дәресе үтте. Бу чаралар барысы да – патриотик аң, гражданлык позициясе тәрбияләүгә беренче адымнар. План нигезендә февральдә хәрби-патриотик айлык үткәрелде. Айлыкта барлык укучылар да актив катнашты. “Әтиләр бәйрәме”, традицион рәвештә мәктәп күләмендә “Аҗаган” хәрби-спорт уены, сугыш һәм тыл ветераннары белән очрашулар тәрбияви һәм кызыклы булды, армиядә хезмәт итүче егетләргә котлау открыткалары җибәрелде. Бөек Җиңүнең 74 еллыгын билгеләп үтүгә әзерлек сентябрь аенда ук башланды. Атна саен һәр сыйныф сәгатенен 10 минуты Бөек Җиңүгә багышланды. Сыйныф җитәкчеләре аерым план төзеп эшне оештырдылар. Бөек Җиңүгә багышланган композицияләр ясалды, бу эшкә әти-әниләрнең ярдәме зур булды. 9 май-Җиңү көне зурлап билгеләп үтелде, тыл ветераннарына котлау открыткалары җибәрелде, Түбән Аты авылы Мәдәният йорты каршындагы сугышта һәлак булган авылдашларыбыз хөрмәтенә куелган һәйкәл янында митинг үткәрелде, әдәби- музыкаль кичә әзерләнде. “Үлемсез полк” хәрәкәтендә катнаштык. Декабрь аенда, Билгесез содат көне уңаеннан, һәйкәлгә чәчәкләр салынды.

Мәктәптә хокук тәрбиясе тарих укытучысы, ФАП мөдире, ПДН, участок вәкиленең тыгыз элемтәсе аша алып барылды. Даими рәвештә әлеге темага багышланган тәрбия дәресләре (“Начар гадәтләрсез тормыш”), танып белү уеннары (“Тәмәкесез тормыш”, “Бала хокуклары”), “Тәмәкегә каршы акция” үткәрелде, сыйныф җитәкчеләре укучыларны хокуклары һәм бурычлары белән таныштырдылар, алар белән берлектә хокукый уеннар, викториналар үткәрелде. Шулай ук район полиция хезмәткәрләре вәкилләре белән дә очрашу бик кызыклы үтте, балалар үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар алдылар. Һәрбер класста ТР-ның 71нче законы буенча ныклы сөйләшүләр булды. Укучыларның сәламәтлеген, иминлеген кайгыртып, ТР-ның 71нче законы үтәлешен истә тотып мәктәп коллективы җаваплылыгында шимбә, каникул, бәйрәм көннәрендә мәдәният йортына рейдлар ясау ныклы системага салынды. Мәктәптә хокук бозуны профилактикалау отряды эшләде. Мәктәп буенча район күләмендә учетта торучы укучылар юк. Укучыларның иминлеген саклау - безнең төп бурыч. Даими участок инспекторы, балигъ булмаган балалар һәм яшьләр белән эшләү бүлеге белән даими элемтәдә торып, берлектә хокук бозуларны булдырмау буенча профилактик чаралар, әңгәмәләр үткәрелә,чыгышлар ясала.

Хокук бозуның бер төре булган коррупция тормышыбызда киң җәелеп килә. Укучылар да бу хакта хәбәрдар, аларга аңлату эшләре алып барыла. Шушы максаттан чыгып, мәктәпнең 2018 – 2019 нчы уку елына коррупциягә каршы көрәш эш планы төзелде. Ата-аналар өчен стендка, мәктәп сайтына материаллар куелды, коррупциягә каршы көрәш атналыгы уздырылды. Атналык кысаларында плакатларга конкурс, укучылардан анкеталар алу, викторина, класс сәгатьләре, ачык дәресләр, сочинение конкурсы, әңгәмәләр, китап күргәзмәләре оештырылды.

Укучыларны тәрбияләүдә спорт-сәламәтләндерү юнәлешенең аеруча роле зур. Төп максаты: яшь буында сәламәт яшәү рәвеше, спортка мәхәббәт тәрбияләү. Шушы максаттан мәктәптә күп төрле ярышлар, бәйгеләр, чаралар үткәрелде. Мәктәп спорт залында даими иртәнге гимнастика ясатылды. Ай саен “Сәламәтлек көне” билгеләп үтелде. Укучылар бик теләп “Милләтләр кроссы”нда, “Татарстан чаңгы юллары – 2019”

ярышында көч сынаштылар. Һәр класс җитәкчесе тәрбия сәгатьләрендә сәламәтлек, начар гадәтләргә, наркоманиягә каршы тәрбияви чаралар үткәрде

Мәктәптә балаларны спортка тарту буенча эш алып барыла. Кайбер спорт төрләре буенча сәләтле укучыларыбыз да шактый. Туризм, көрәш буенча район күләмендә үткәрелгән спорт ярышларында да катнашып призлы урыннар яулаган укучыларыбыз саны елдан-ел арта .

Укучыларның сәламәт яшәү рәвешен күздә тотып, мәктәптә "Путь к успеху" программасы буенча эш алып барылды. Әлеге программага караш укучылар, эти-әниләр тарафыннан да елдан-ел ныгый бара. Шул юнәлештә һәрбер класс үзенең планын булдырды, план нигезендә тәрбия дәресләрен үткәрү системага салынды.Уку елы башында һәм ахырында эти-әниләргә анкеталар үткәрелде, нәтиҗәләр билгеләнде.

Тәрбиянең хезмәт юнәлеше буенча традицон рәвештә үткәрелгән чаралар:

- Өмәләр;
- Классларда җыештырулар;
- Өлкәннәргә ярдәм операциясе;
- Мәктәп территориясен яшелләндерү;
- Чәчәкләр, гөлләр утырту;
- Мәктәп яны тәҗрибә участогында эшләү;
- Бөек Ватан сугышында һаләк булган ветераннарыбыз истәлегенә куелган һәйкәлне тәртиптә тоту.

Класстан тыш вакытта мәктәптә профориентация буенча ел саен системалы һәм планлы тәрбия эше алып барыла. Бу уку елы башында һөнәр сайлауга юнәлеш бирү планы төзелеп, шул план нигезендә эшләнде.Укучыларда авыл хуҗалыгына караган һөнәрләргә карата кызыксыну уяту, киләчәктә оешмаларга кирәк булган хезмәт ияләре турында әңгәмә үткәрү, укучыларга берникадәр һөнәри юнәлеш бирү кебек эшләр башкарылды. Класс җитәкчеләре класс сәгатьләрендә "Мин һәм минем һөнәрем", "Мин кем булырга телим?", "Әтиләр эшен дәвам итәбез", "Һөнәрле үлмәс,һөнәрсез көн күрмәс" һ.б. темаларга төрле чаралар үткәрделәр. "Киләчәккә билет" сочинениеләр конкурсында катнаштык.

Укытучы тарафыннан ныклы караш, күп көч сорый торган юнәлеш – әхлак тәрбиясе.

Бу уңайдан мәктәпнең тәрбия планында төрле кичәләр урын алган:

Тәрбия дәресләре –"Яхшы кеше нинди була?", "Нәрсә ул яхшы, нәрсә ул яман" һ.б;Бәйрәмнәр –Әниләр көне;Укытучылар бәйрәме; Гаилә көне;

Май аенда мәктәпкә бер төркем язучылар килеп, укучылар, укытучылар белән очраштылар, алар үз әсәрләрен укыдылар, укучыларның сорауларына җаваплар бирделәр.

Укучыларда халык традицияләрен саклау максатыннан – "Сөмбелә" бәйрәме, татар шагыйрләренең туган көннәре олылап билгеләнә,Тукай көннәре.

5,6 нчы класс укучылары "Секреты дружного класса", " Без бергә"конкурсында катнаштылар.

Барлык үткәрелгән тәрбия эшчәнлеге нәтиҗәсе укучыларның тәрбиялелек дәрәҗәсендә чагыла. Әлеге юнәлешләрне, үткәрелгән чараларны истә тотып, 1-9 классларда класс җитәкчеләре тарафыннан укучыларның тәрбиялелек дәрәҗәсе билгеләнде. Әлеге эштә укучыларның укуга, хезмәткә, гомуми чараларга, дусларга, спортка мөнәсәбәте исәпкә алынды.

Тәрбия эшчәнлегенең мавыктыргыч юнәлеше – эстетик юнәлеш. Төп бурычлары булып, мәктәпнең, классның иҗади эшчәнлегенә укучыларны тарту, буш вакытларын кызыклы, файдалы итеп үткәрүләренә ирешү, эстетик сыйфатлар, зәвык, сәнгатьтә һәм тормышта гүзәллекне аңлый һәм тудыра белү,тормышны матурлык кануннары нигезендә кора белү сыйфатлары формалаштыру тора.

Бу юнәлештә укучыларны җәлеп иткән төп чараларга походлар; музейларда булу; сәнгать кешеләре белән очрашулар; төрле бәйрәмнәр үткәрү керә.

Укучыларыбыз җыр-биюгә, шигырь сөйләргә бик оста. Араларында район сәхнәләрендә үз сәләтләрен күрсәткән һәм уңышларга ирешкән укучыларыбыз да бар. Экологик юнәлешнең төп бурычы табигатьне аңларга, яратырга өйрәтү , укучыларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. Бу юнәлеш буенча мәктәптә максатчан һәм экологик программа нигезендә эш алып барылды. Сентябрь аенда “Планетаны чүптән чистартыйк” акциясе кысаларында Чисталык дәресләре үткәрелде. Эш планы төзелде һәм мәктәптә күп төрле чаралар үтте. Ә март ае тулысы белән табигать ае дип игълан ителде һәм укытучылар балалар белән “Урман көне”н билгеләп үттеләр. Башлангыч сыйныфлар атналыгы да экологик тәрбиягә багышланган иде. Бу класс җитәкчеләре кызыклы һәм мавыктыргыч итеп, “Кошлар – безнең дусларыбыз”, “Су – яшәү чыганагы”, “Урман сукмагы буйлап”, “Чәчәкләр бәйрәме” кебек класс сәгатьләре үткәрделәр. Май аенда мәктәбебез укучылары агач утырту акциясендә катнашып, агач утыртты.

Тәрбия системасының мөһим тармакларыннан берсе укучылар үзидарәсе һәм укучылар оешмасы эшчәнлеге. 2016-2017 нче уку елында “Факел” укучылар оешмасы түбәндәге юнәлешләр буенча эшләде:

- хезмәт юнәлеше , кайгырту юнәлеше (тимурчылык эше, өлкәннәргә шефлык), иҗадилык юнәлеше, лидерлык юнәлеше (укучылар үзидарәсе эшчәнлеге, класс активларының эшчәнлеге, анкеталар алу, сайлаулар уздыру, вожатыйлар эшчәнлеге). Югары класс укучыларыннан торган үзидарә төрле бәйге-кичәләрдә, мәктәп күләмендә үткәрелә торган конкурс- акцияләрдә активлык күрсәтте. Мәктәп тормышында үткәрелә торган традиион бәйрәмнәрне үткәрү тәртибе үзидарәдә каралды, членнарның фикер-планнары кабул ителде.

Укучыларның буш вакытларын файдалы уздыру өчен шартлар тудырылган. Мәктәбебездә түгәрәкләр эшләде.

Уку елы дәвамында эти-әниләр белән эш алып баруда түбәндәге бурычлар куелган иде:

1) Һәр гаиләдә балаларны тәрбияләү системасын өйрәнү;

2) эти-әниләр белән берлектә укучыларның сәләтләрен ачыклау һәм үстерү өстендә эшләү

3) эти-әниләрнең мәктәп тормышына актив катнашуына ирешү.

Алынган бурычлар тулысынча үтәлде дип әйтергә була. Ел буена үткәрелгән тәрбия чараларында эти-әниләр актив катнашырга тырыштылар. “Әниләр бәйрәме”, “Әтиләр кичәсе” кебек мәктәпкүләм чаралар үткәрелде. Классларда ата-аналар укуы системалы рәвештә алып барылды. Ата-аналар җыелышларында балаларның педагогик - психологик үзенчәлекләрен өйрәнү, кызыксынучанлыкларын һәм сәләтләрен ачыклау буенча эш алымнары белән таныштыру, гаиләдә әхлаклылык торышы, сәламәтлек һәм сәламәт яшәү рәвеше темаларына сөйләшүләр үткәрелде. “Путь к успеху” республика программасы буенча ата-аналар укуы, тематик әңгәмәләр, анкеталар үткәрелде. Ата – аналар арасында балаларның наркотик матдәләр куллануы профилактикасы буенча аңлату эшләре алып барылды. Ел саен мәктәпнең социаль паспорты яңартыла. Әз керемле, “риск” төркемле, мөмкинчелеге чикләнгән, тулы булмаган, күп балалы гаиләләр төркеме ачыкланды.

***Тәкъдимнәр:***

1. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау максатыннан эти-әниләр, җәмәгатьчелек белән берлектә сәламәтлек көннәре үткәрү кирәк.
2. Укучыларның кызыксынучанлыкларын һәм сәләтләрен үстерү максатыннан төрле дәрәҗәдәге чаралар үткәрү, “Юнармия” отрядының эшен активлаштыру.
3. Тәрбия бирүнең төрле ысулларын һәр дәрестә файдалану өчен укытучыга эзләнергә, иҗади табышлар кулланырга .
4. Укучыларны әхлакый яктан үстерү,аларда үз милләтенә, теленә,тарихына карата хөрмәт булдыру аша тәрбиялелек дәрәҗәсен күтәрү өстендә эшләргә.

**Нәтиҗә:**

Мәктәп укыту-тәрбия процессының бөтен баскычларында укучыларны укыту һәм тәрбияләүнең төп мәсьәләләрен үти.

## *III Җитешсезлекләр.*

Соңгы нәтиҗәләрдәге кимчелекләр.

1. **Белемлелек**

Күрсәтелгән уңышлар белән бергә кайбер кимчелекләр дә бар. 4 укучы берәр генә фәннән (рус теле, инглиз теле,математика) алдынгылар сафыннан төшеп калды. Класс җитәкчеләренә фән укытучылары белән ныграк элемтәдә торырга кирәк.

Йомгаклау контроль эшләре күрсәткәнчә, Физика һәм химиядән күрсәткечләр сыйфат ягыннан түбән: сыйфат 46% һәм 33%. Физика һәм химия укытучыларына сыйфатны күтәрү ягыннан күп эшлисе бар.

Сыйфат буенча аеруча 7 һәм 8 класста физикадан (сыйфат 25% һәм 14%), VI класста инглиз теленнән (сыйфат 50%) күрсәткечләр түбән.

Иң түбән күрсәткеч VI класста, гомуми сыйфат 50%, өлгереш 100% тәшкил итә. Бу - калган класслар белән чагыштырганда түбән күрсәткеч .

VIII класс укучысы Хабибрахманов Азат, VI класс укучысы Габдрахманов Рөстәмнең белем дәрәҗәсе түбән булып кала бирә. Укучыларның дөрес һәм матур язу күнекмәләрен уңай якка кертеп бетерә алмыйбыз.

Бу җитешсезлекләрне бетерү өстендә бөтен классларда барлык фәннәр буенча эш алып барырга кирәк.

2. **Тәрбиялелек.**

Мәктәптә тәрбия эше берөзлексез алып барыла. Һәр дәрес, һәр үткәрелгән чара бала тәрбияләүгә юнәлдерелгән. Шуның аркасында мәктәптә җәмәгать тәртибен бозучылар, милициядә учётта торучылар юк. Укучылар күп дәрес калдыралар.

Әмма өлкән класс укучыларының кич чыгып йөрүләре уку сыйфатын төшерүгә китерә.

Хезмәт тәрбиясе бирү җайга салынган, әмма профориентацион тәрбия бирү өстендә әле җитәрлек дәрәҗәдә үк эш алып барылмый. Укучыларда мөстәкыйльлек, инициатива җитми.

Экологик тәрбия юнәлешендә күпмедер эш алып барыла. Әмма утыртылган агач – куакларның үсү – үсмәүләре контрольдә тотылмый, чишмәләр даими чистартып торылмый.

Класс җитәкчеләре тарафыннан укучыларның өйләренә рейдлар системалы оештырылмый. Әти-әниләр белән даими элемтә булдыру кирәк.

Укучылар белән үткәрелгән һәр тәрбия сәгате турында материал, аның эчтәлеге укытучының махсус дәфтәрендә теркәлеп барылса иде.

Кыш көне безнең якларда кышлаучы кошларга ярдәм күрсәтү җитәрлек дәрәҗәдә түгел.

Яз көннәрендә укучыларның бик азы гына сыерчык оялары ясый.

Укучыларны хәрби хезмәткә әзерләү эшен җайга саласы бар. Мәктәп милкенә сакчыл караш булдыру-төп бурычларыбызның берсе.

2019-2020нче уку елына мәктәпнең методик темасы “Икенче буын ФДББСын тормышка ашыру шартларында укыту-тәрбия процессында заманча педагогик технологияләр кулланып, укучыларның сәләтләрен, укытучы потенциалын үстерү” итеп кала

Мәктәп коллективының 2019-2020нчы уку елына максат һәм аны тормышка ашыру буенча бурычлар**.**

**Максат:** мәктәп системасы шартларында дәүләт стандартларын уңышлы үзләштерүче, сәламәт яшәү рәвеше алып баручы, сәләтле, иҗади шәхес формалаштыру.

1. Мәктәп микрорайонындагы һәр баланың түләүсез тө белем алуына ирешүне дәвам итү. Укучыларга ныклы, сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү. Төп дәүләт имтиханнарына әзерләүне көчәйтү.

2. Укыту процессында заманча инновацион технологияләр куллану. Электрон белем бирү системасында һәр укытучыга, сыйныф җитәкчесенә, укучыларга электрон журнал һәм электрон көндәлек белән эшне системалы рәвештә алып бару.

3. Балалар сәламәтлеген ныгыту һәм саклау өстендә эш алып бару.

4. Укытучыларның профессиональ конкурсларда, республика грантларында нәтиҗәле катнашуына ирешергә.

5. Дәрестән соң балаларның буш вакытларын нәтиҗәле файдалану өчен яшүсмерләрне иҗади, фәнни-эзләнүле, проект эшчәнлегенә, техник иҗатка киңрәк тарту.

6. Сәләтле балалар белән эшне дөрес итеп оештыру, конкрет план һәм программалар нигезендә укучыларның сәләтен үстерү өлкәсендә системалы эшне алып бару. Укучыларның район, республика һәм бөтенроссия күләмендә үткәрелә торган фән олимпиадаларында катнашуның сыйфатын күтәрү.

7. Укыту- тәрбия процессында патриотик һәм милли компонентлар куллану.

8. Төп белем баскычында бердәм дәүләт белем стандартларын кертүне дәвам итү.

9. Гаиләләр белән тыгыз элемтә урнаштырыу, тәрбия эшендә гаилә тәҗрибәсен, аларның шәхси үрнәген куллану.